РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423950, п.г.т. Уруссу, ул. Пушкина, д.38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

423950, Урыссу ш.т.б., Пушкин урамы, 38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20


**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 29 » 09 2023 г. №1502

2023 елның IV кварталына Ютазы
муниципаль районы буенча
торак мәйданының 1 квадрат метрының
уртача базар бәясен раслау хакында

«Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2007 елның 13 июлендәге 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары өчен Социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарны торак урыннарына мохтаҗ дип тану һәм аз керемле дип танылган гражданнарга социаль наем шартнамәләре буенча торак урыннар алуга исәпкә кую һәм торак урыннар бирү максатларында гражданнарны аз керемле дип тану тәртибен билгеләү буенча методик тәкъдимнәр, шулай ук торак кодексының 49, 51 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Ютазы муниципаль районында «Татарстан Республикасы бәяләүчеләре берлеге» Коммерцияле булмаган партнерлыгы тарафыннан торак урыннарның 1 квадрат метры бәясенең уртача күрсәткечен билгеләү буенча тикшерену нәтиҗәләренә ярашлы рәвештә, 2023 елның IV кварталына Ютазы муниципаль районы буенча торак урынның гомуми мәйданының 1 квадрат метрының бәясе нормативын - 40 571 сум күләмендә билгеләргә.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча бастырып чыгарырга һәм http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Рәсми Татарстан» дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының бердәм порталы составында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Башкарма комитеты
җитәкчесе С.П. Самонина

С.Р. Сәетгәрәева
8(85593)2-42-05